**Задания заключительного тура Акмуллинской олимпиады по татарскому языку и литературе для учащихся 10-11 классов, студентов СПО**

1. Буш урыннарга исемнәрнең данә исәбен белдергән сүзләрне куегыз (5 б):

1 капчык ... шикәр 1 кочак ... утын
икмәк ... сыныгы 1 тотам ... йон
1 уч ... бодай арыш .... көлтәсе
кар ... өеме 2 кап ... шырпы
10 баш ... суган чәчәк ... бәйләме

2. Саннар артына яшеренгән мәкальне табып языгыз (10 б).

1, 12 38, 13, 23, 34, 21, 23, 13, 1, 16, 6, 1 12, 18, 14, 6, 34, 10 13, 25, 7, 36, 15, 11.

____________________________________________________________.

3. Канатлы сүзләрне рус теленә тәрҗемә итегез: (12 б)

Ахиллес үкчәсе ахиллесова пята,
Шөкатьсез үрдәк баласы гадкий утёнок,
Дары мичкәсендә дары бар әле есть еще порох в пороховницах.
Очкыннан ялкын кабына из искры возгорится пламя
Крокодил күз яше крокодиловы слезы,
Аю хезмәте күрсәтү оказать медвежью услугу.

4. Түбәндәге формулаларга туры килгән сандхи очракларына 1-әр мисал китерегез (3+3=6):

е + ә = ә биә әле
ы+у=у сары ут

5. Дөрес җавапны билгеләгез (4 б.):

*Бергә алар язгы урман һавасы суладылар, яр буенда саргылт тал ПИПИЛӘРЕ өзделәр* (Н.Фәттах). Җөмләдә аерып бирелгән сүз:

- профессионализм
- архаизм
- диалектизм ✓
- неологизм

Алар билгеле бер формага буйсынган булалар. Аларда мәҗбүри җөмлә калыплары, сүзтезмәләр, тәгъбирләр кулланыла, алардан зур төгәллек сорала.

- матур әдәбият әсәрләре
- рәсми эш кәгазьләре
- публицистик әсәрләр ✓
- драма әсәрләре

Бирелгән кереш сүзләр нинди мәгънә белдерәләр?

*ихтимал, күрәсең, бәлки, ахрысы, ахры*

– билгесезлекне ✓

– үтенүне

– сөйләүченең төрле тойгысын

– фикер эзлеклелеген

Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" әсәренең тулы текстын беренче булып кульязмада әзерләгән әдип:

– С.Сараи

– Г.Утыз Имәни ✓

– Й.Баласагунлы

– Колшәриф

6. Дөрес җавапларны билгеләгез: (3 б)

1. Әсәрләрнең жанрын языгыз:

"Сөннәтче бабай" повесть

"Беренче театр" комедия

"Сак-Сок" бәет

7. Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» драмасында автор югары күтәргән сыйфатлар (1 сыйфат – 1 б. =5 б.).

Намуслы, гади, чыдам, үлемсез, зирәк, шаян, киң күңелле, эш сөючән, акыллы, көчле рухлы, озын гомерле, ачык йөзле, шәфкатьле, йомшак күңелле, эшчән, тынгысыз

8. М. Акмулла "Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт берлән" дип язган. Автор турында 5 факт яз (10 б.)

1) Акмулла - татар, башкорт һәм казакъ халыкларының уртак шагыйре 2) 1831 елның 27 декабрендә Оренбург губернасының Бәләбәй өязе Түксанбай авылында туа. 3) Мулла гаиләсендә туган. 4) 1895 елның 27 октябрендә Златоусттан Миасска барганда, билгесез кешеләр тарафыннан үтерелә. 5) Шагыйрьнең иң беренче басылган шигъри әсәрләренең берсе - "Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе".

9. Җәяләрне ачып, дөрес языгыз (5 б).

(1) Сулар ага... (2) Җир (йөзендә) йөзендә сулар бер (туктаусыз) бертуктаусыз агалар (да) агалар. агалар да (3) Җәй агалар, яз агалар, көз агалар... (4) Агым сулар кешеләрнең чир (чорларын) чир-чорларын кайгыларын, языкларын алалар (да) алалар да ераклрга, упкыннарга, чоңгылларга ыргыталар. (5) Агым сулар, җир (өстенең) өстенең чүп (чарларын) чүп-чарларын юып алып, үзләрендә юк итәләр. (6) Шулай ел (да) ел да җир яңара, җир яшәрә.

(7)Җир яңара, җир яшәрә... (8)Өзелмичә, туктамыйча, бөек Чулман кебек, Әтил кебек, көн (төн) көн-төн җирдә тормыш ага.

(9)Яз килде, яз!... 10)Киң Чулманга – кояш белән, ай (йолдызлар) ай-йолдызлар белән яшьтәш Чулманга ашыгып төрле (яктан) сулар ага...(Н. Фәттах).

төрле яктан

10. Бирелгән өзек нинди әсәрдән? (2 б.) „Итил суы ака торур" романы

11. Түбәндәге тел күренешләре булган җөмлә номерларын куярга (5 б):

1) ялгызлык исемнәре
2) парлы сүзләр
3) гөнаһ сүзенә синоним
4) юклык формасындагы фигыль
5) вакыт мәгънәсен белдергән исем

| 1) | 2) | 3) | 4) | 5) |
|---|---|---|---|---|
| 8,9 | 4,5,8,10 | 4 | 8 | 6 |

12. 5нче җөмләдә хәбәрнең төре (3 б.) кушма фигыль хәбәр

13. Өзекне дәвам итеп эссе языгыз. Күләме 200 сүздән ким булмаска тиеш (30 б.)

Сулар аккан кебек, еллар үткән. Татар халкы бик күп тормыш сынаулары үтеп, бүгенге көнгәдә килеп җиткән. Гасырлардан - гасырга, буыннан - буынга, үзләренең борынгы бабаларының, гореф-гадәтләрен, йолаларын югалтмыйча тапшырып килгән һәм һәрвакыт аның ирекка, азатлыкка омтылышы да югалмаган.

Н. Фәттахның тарихи романы безгә гасырлар аша килгән хәбәр. Аны укыганда тарих чоңгылына чумасың. Татар халкы гасырлар дәвамында дәүләтчелеккә ия булган. Аның даны ия да, фаҗигале дә тарихы бар. Шуның бер дәверен тасвирлау аша Н. Фәттах халкыбызның үз дәүләтчелегенә тиры хокукы барлыкын раслый. Безне иманлы, әхлакый яшәешкә, үз милләтебезне сакларга өнди, бердәмлек идеясын кайнар яклый. Итил суы агып торган кебек еллар, заманнар үтә, безнең күз алдыбызда бөртәм вакыйгалар да тарихта кала. Табигать күренешләреннән аермалы буларак, кеше гамәре

шактый кыска, шуңа күрә аны максатчан һәм мәгънәле итеп үткәрергә кирәк. Яшәү мәгънәсе кеше өчен бик мөһим. Меңәрле туа, балага әверелә, үсмер, бала, аннары өлкәннәргә әйләнә. Кешенең иң матур истәлекле, иң изге хыяллары, иң беренче шатлык-куанычлары аның балачагы яки үсмер чоры белән бәйләнгән була. Шуның өчен үк кечкенәдән үзеңдә күркәм сыйфатлар: гаделлек, тыйнаклык, хезмәт сөючәнлек, кыюлык тәрбияләп, чын кеше булып үсәргә тиеш. Минем уйлавымча, һәрбер кеше кайчандыр үзенә яшәү мәгънәсен таба. Кемдер яшәү мәгънәсен гаиләсе булуда, карьерасында, эшендә, халыкка намуслы хезмәт итүендә, туган телен яратуында һ.б. таба. Һәр тормыш мәгънәсе үзенчә мөһим. Тик намусыңны саф көе саклап калырга омтылырга, туган телеңне, аның тарихын онытмаска кирәк.